**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2019 ел № 38

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының кайбер карарлары үз көчләрен югалтуны тану турында

1. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре бюджетыннан социаль характердагы чаралар уздырганда хезмәт күрсәтүләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнарны каплау максатларында субсидия бирү тәртибе турында» 2017 елның 26 июнендәге 21 нче номерлы карары;

- Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 26 июнендәге 21 нче номерлы «Азнакай муниципаль районы бюджетыннан социаль характердагы чаралар уздырганда хезмәт күрсәтүләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнарны каплау максатларында субсидия бирү тәртибе турында» карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы бюджетыннан социаль характердагы чараларны үткәргәндә хезмәт күрсәтүләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнарны каплау максатларында субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 04 сентябрендәге 24 нче номерлы карары;

- «Экологик икеайлык чорында стихияле чүплекләрне юкка чыгарганда хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнарны каплауга Азнакай муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2017 елның 24 июлендәге 23 нче номерлы карары;

- Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан шәһәрнең социаль әһәмияткә ия объект- мунча төзекләндерүгә һәм ремонтлауга бәйле рәвештә барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 22 ноябрендәге 30 нчы номерлы карары.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.И. Солтанов